РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ
БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422065, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большие Кибячи, ул.Ф.Энгельса, 21
тел. (84362) 42-6-24

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422065, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс урам, 21 йорт
тел. (84362) 42-6-24

e-mail: Bkib.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
19.10.2022

КАРАР
№15

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Кибәче авыл җирлеге Советының 2018 нче елның
28 нче апрелендә кабул ителгән 8 нче номерлы
«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Кибәче авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының
депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм
муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары
турында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2022 №881 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советы

Карар итте:

1. 2022 елның 1 октябреннән Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының 28.04.2018 ел, № 8 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затлары һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» гә таянып, Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен 1,04 тапкырга арттырырга.

2. 2022 елның 1 октябреннән Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә»не 28.04.2018 № 8 карары белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең вазыйфа окладлары күләмен арттырырга.

3. Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары күләмнәрен исәпләү өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме билгеченең

вазыйфа оклады күләмен 1,04 тапкыр индексацияләргә һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

4. Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының 28.04.2018 № 8 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә" (Олы Кибәче авыл җирлеге Советының 09.11.2020 елгы №11 карары редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазифа окладын 11 958 сум күләмендә расларга.»;

4.2.1нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә, әлеге карар өчен 1нче кушымта нигезендә җиткерергә.

5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2022 елның 1 октябреннән гамәлдә булу башлангач, яңа штат расписаниеләрен расларга.

6. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү, тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге карар 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә гамәлгә ашырыла.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru һәмТатарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/kibiachi адреслары буенча бастырып чыгарырга.

Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгы А.К. Сафин

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының 2022 елның 19 октябре, № 15 карарына

Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләкләре күләме

| Вазыйфалар исемнәре акчалата бүләк күләме (сумнарда) | акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 16390 |
| Депутатлар | 11958 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 11958 |